**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
16 марта 2022 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 27 (часть I), № 55 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 36 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 17 (часть I) следующие изменения:

1) в пункте 37 части 1 статьи 15 слова «, проведение открытого аукциона на право заключить договор о создании искусственного земельного участка» исключить;

2) в пункте 32 части 1 статьи 16 слова «, проведение открытого аукциона на право заключить договор о создании искусственного земельного участка» исключить;

3) в пункте 41 части 1 статьи 17 слова «, проведение открытого аукциона на право заключить договор о создании искусственного земельного участка» исключить;

4) статью 33 дополнить частью $5^1$ следующего содержания:

«$5^1$. Проведение проверки соответствия кандидатов на замещение должности руководителя финансового органа муниципального района, городского округа Республики Татарстан квалификационным требованиям осуществляется с участием финансового органа Республики Татарстан. Порядок участия финансового органа Республики Татарстан в проведении указанной проверки устанавливается приложением 3 к настоящему Закону.»;

5) дополнить приложением 3 следующего содержания:

«Приложение 3
к Закону Республики Татарстан
«О местном самоуправлении
в Республике Татарстан»

**Порядок**
**участия финансового органа Республики Татарстан в проведении проверки соответствия кандидатов на замещение должности руководителя финансового органа муниципального района, городского округа Республики Татарстан квалификационным требованиям**

1. Финансовый орган Республики Татарстан участвует в проведении проверки соответствия кандидатов на замещение должности руководителя финансового органа муниципального района, городского округа Республики Татарстан (далее – кандидаты) квалификационным требованиям на основании обращения главы муниципального района, городского округа Республики Татарстан (далее – глава муниципального образования).

2. Участие финансового органа Республики Татарстан в проведении проверки кандидатов осуществляется путем проверки соответствия представленных главой муниципального образования кандидатов квалификационным требованиям, установленным уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти (далее – квалификационные требования).

3. Проверка соответствия кандидатов квалификационным требованиям осуществляется квалификационной комиссией, создаваемой в финансовом органе Республики Татарстан. Положение о квалификационной комиссии утверждается финансовым органом Республики Татарстан. По результатам проверки принимается заключение финансового органа Республики Татарстан по форме согласно приложению к настоящему Порядку.

4. К обращению главы муниципального образования прилагаются следующие документы кандидатов:

1) заверенные нотариально или кадровой службой по месту работы (службы) копии документов об образовании и о квалификации, выданных по результатам успешного прохождения государственной итоговой аттестации, подтверждающих наличие у кандидата высшего образования не ниже уровня специалитета,

магистратуры по специальности, направлению подготовки, входящим в укрупненные группы специальностей и направлений подготовки «Экономика и управление», либо диплома кандидата экономических наук;

2) заверенная нотариально или кадровой службой по месту работы (службы) копия трудовой книжки (при наличии) либо сведения о трудовой деятельности, оформленные в установленном законодательством порядке;

3) письменное согласие кандидата на обработку персональных данных;

4) обоснование назначения кандидата на должность руководителя финансового органа муниципального района, городского округа Республики Татарстан.

5. В целях проверки профессиональных знаний кандидата, необходимых для исполнения соответствующих должностных обязанностей, квалификационной комиссией проводятся тестирование и индивидуальное собеседование с кандидатом.

6. Примерный перечень вопросов, необходимых для проведения тестирования кандидатов, размещается на официальном сайте финансового органа Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

7. Срок проведения квалификационной комиссией проверки и подготовки заключения финансового органа Республики Татарстан не может превышать 30 рабочих дней со дня поступления обращения главы муниципального образования в финансовый орган Республики Татарстан.

8. Квалификационная комиссия по результатам проверки принимает одно из следующих решений:

1) о соответствии кандидата квалификационным требованиям;

2) о несоответствии кандидата квалификационным требованиям.

9. Заключение финансового органа Республики Татарстан не позднее трех рабочих дней со дня его утверждения направляется главе муниципального образования, направившему обращение.

Приложение
к Порядку участия финансового органа Республики Татарстан
в проведении проверки соответствия кандидатов на
замещение должности руководителя финансового
органа муниципального района, городского округа
Республики Татарстан квалификационным требованиям

«Утверждаю»

____________________________________

(руководитель финансового органа
Республики Татарстан)

«___»____________ 20______ года

______________________________________________________________________________

(наименование финансового органа
Республики Татарстан)

Заключение № ____
о результатах проверки соответствия кандидата на замещение должности руководителя финансового органа муниципального района, городского округа Республики Татарстан квалификационным требованиям

г. Казань «_____»___________ 20___ года

____________________________________________________________
(наименование финансового органа Республики Татарстан)
рассмотрено обращение главы муниципального образования
____________________________________________________________
(наименование муниципального района, городского округа Республики Татарстан)
о проведении проверки соответствия кандидата
____________________________________________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии)
квалификационным требованиям на замещение должности руководителя финансового органа
____________________________________________________________
(наименование муниципального района, городского округа Республики Татарстан).

На основании представленных документов и с учетом проведенного тестирования и индивидуального собеседования рассмотрен вопрос о соответствии кандидата
____________________________________________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии)
на замещение должности руководителя финансового органа
____________________________________________________________
(наименование муниципального района, городского округа Республики Татарстан)
квалификационным требованиям.

В ходе проверки установлено соответствие/несоответствие квалификационным требованиям (нужное подчеркнуть).

Кандидат__________________________________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии)
соответствует/не соответствует (нужное подчеркнуть) квалификационным требованиям на замещение должности руководителя финансового органа
____________________________________________________________
(наименование муниципального района, городского округа Республики Татарстан).

В ходе проверки установлено несоответствие следующим квалификационным требованиям <*>:

1)________________________________________________________
2)________________________________________________________
3)________________________________________________________
4)________________________________________________________

--------------------------------

<*> Заполняется при установлении несоответствия кандидата квалификационным требованиям.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
24 марта 2022 года
№ 15-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 16 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендәге 37 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«37) федераль закон нигезендә җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү;»;

2) 16 статьяның 1 өлешендәге 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«32) федераль закон нигезендә муниципаль район ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү;»;

3) 17 статьяның 1 өлешендәге 41 пунктны түбәндәге редакциядә бән итәргә:
«41) федераль закон нигезендә шәһәр округы ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча кирәкле эшләр башкаруны тәэмин итү;»;

4) 33 статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы финанс органының күрсәтелгән тикшерүне үткәрүдә катнашу тәртибе әлеге Законга 3 нче кушымтада билгеләнә.»;

5) түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы финанс органының Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрүдә катнашу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы финанс органы Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның (алга таба – кандидатлар) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрүдә Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы башлыгы (алга таба – муниципаль берәмлек башлыгы) мөрәҗәгате нигезендә катнаша.

2. Татарстан Республикасы финанс органының кандидатларны тикшерүдә катнашуы муниципаль берәмлек башлыгы белән тәкъдим ителгән кандидатларның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

3. Кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне Татарстан Республикасы финанс органында төзелә торган квалификация комиссиясе гамәлгә ашыра. Квалификация комиссиясе турында нигезләмә Татарстан Республикасы финанс органы тарафыннан раслана. Тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән рәвештә Татарстан Республикасы финанс органы бәяләмәсе кабул ителә.

4. Муниципаль берәмлек башлыгы мөрәҗәгатенә кандидатларның түбәндәге документлары кушып бирелә:

1) кандидатның белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең «Икътисад һәм идарә» берләштерелгән төркеменә керә торган белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә белгечлек, магистратура дәрәҗәсендәге югары белеме булуын раслый торган, дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы узу нәтиҗәләре буенча белем турында һәм квалификация хакында бирелгән документларның йә икътисад фәннәре

кандидаты дипломының нотариус яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

2) хезмәт кенәгәсенең (булганда) нотариус яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яисә хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;

3) кандидатның шәхси белешмәләрне эшкәртүгә язмача ризалыгы;

4) кандидатны Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куюны нигезләү.

5. Кандидатның тиешле вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәрен тикшерү максатларында квалификация комиссиясе тарафыннан кандидатка тест һәм индивидуаль әңгәмә үткәрелә.

6. Кандидатларга тест үткәрү өчен кирәкле сорауларның якынча исемлеге Татарстан Республикасы финанс органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

7. Квалификация комиссиясе тарафыннан тикшерү үткәрү һәм Татарстан Республикасы финанс органының бәяләмәсен әзерләү срогы муниципаль берәмлек башлыгының мөрәҗәгате Татарстан Республикасы финанс органына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә артыграк була алмый.

8. Квалификация комиссиясе тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кандидатның квалификация таләпләренә туры килүе турында;

2) кандидатның квалификация таләпләренә туры килмәве турында.

9. Татарстан Республикасы финанс органы бәяләмәсе, расланган көненнән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгатьне җибәргән муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

Татарстан Республикасы финанс органының
Татарстан Республикасы муниципаль районы,
шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын
биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә
туры килүен тикшерүне үткәрүдә катнашу тәртибенә
кушымта

«Раслыйм»

________________________________

(Татарстан Республикасы
финанс органы җитәкчесе)

20____ елның «___» ___________

____________________________________________________

(Татарстан Республикасы
финанс органы исеме)

Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү нәтиҗәләре турында
бәяләмә № ____

Казан шәһәре 20___ елның «_____»___________

___________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы финанс органы исеме)

___________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге, шәһәр округы исеме)
финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидат

___________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү үткәрү турында

___________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге, шәһәр округы исеме)
муниципаль берәмлеге башлыгы мөрәҗәгате каралды.
Тәкъдим ителгән документлар нигезендә һәм үткәрелгән тест нәтиҗәләрен һәм индивидуаль әңгәмәне исәпкә алып,

___________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге, шәһәр округы исеме)
финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидат

___________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
квалификация таләпләренә туры килүе турындагы мәсьәлә каралды.

Тикшерү барышында квалификация таләпләренә туры килү/туры килмәү билгеләнде (тиешлесенең астына сызарга).

___________________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге, шәһәр округы исеме)
финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидат___________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
квалификация таләпләренә туры килә/туры килми (тиешлесенең астына сызарга).

Тикшерү барышында түбәндәге квалификация таләпләренә туры килмәү билгеләнде<*>:

1)___________________________________________________________________
2)___________________________________________________________________
3)___________________________________________________________________
4)___________________________________________________________________

--------------------------------

<*> Кандидатның квалификация таләпләренә туры килмәве билгеләнгәндә тутырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 24 март
№ 15-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ